**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 июнь № 411

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алуны иң яхшы оештыру һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында республика конкурсы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елда Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алуны иң яхшы оештыру һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында республика конкурсы үткәрергә.

2. Теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алуны иң яхшы оештыру һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында республика конкурсы турында нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алуны иң яхшы оештыру һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында республика конкурсының приз фондын финанслар белән тәэмин итү «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы» ведомствосы буенча «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларны җайга салу өлкәсендә аерым чаралар» максатчан статьясында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алуны иң яхшы оештыру һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр

округлары арасында республика конкурсында катнашуын оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы санын алуны иң яхшы оештыру һәм үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары арасында республика конкурсын әзерләү һәм оештыруны массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктыртуны оештырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков